Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль район Советы
КАРАРЫ

19 февраль 2019 ел №272

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында отчеты

Әлмәт муниципаль районы Башлыгы А.Р. Хәйруллинның 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында отчетын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Әлмәт муниципаль район Советы, район Башлыгының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын билгели.

2018 ел Әлмәт муниципаль районы өчен ике истәлекле дата – шәһәр төзелүнең 65 еллыгы һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын сәнәгый эшкәртә башлауның 75 еллыгы белән истә калды.

Хисап елында район Башлыгының эшчәнлеге халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуга һәм районның киләчәк үсеше өчен конкурентлылык сәләтен арттыруга юнәлдерелгән уңай шартлар тудыру өчен җирле үзидарә органнарының тырышлыгын координацияләүгә юнәлдерелгән иде.

Эш республика җитәкчелеге, «Татнефть» компаниясе, депутатлар корпусы, районның хезмәт коллективлары һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнештә алып барылды. Стратегик үсеш курсын алып, билгеләнгән төп планнарны тормышка ашырырга мөмкинлек булды.

Озак сроклы перспективада район үсешенең өстенлекле юнәлешен 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш стратегиясе билгели. Әлмәт муниципаль районы югары позицияне саклый һәм лидерлар рәтендә кала. Социаль-икътисадый үсеш рейтингында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында район 2 нче урында.

Елның төп казанышлары: «Сыйфат өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте премиясе» бәйгесендә һәм «Акыллы стратегия-акыллы шәһәр» номинациясендә бөтенроссия муниципаль стратегияләр бәйгесендә җиңү, «ЭКОлидер» республика бәйгесендә «Әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендәге казанышлары өчен» номинациясендә беренче урын, «Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты» республика бәйгесенең III дәрәҗә

дипломын алу, Әлмәтнең спорт һәм ял инфраструктурасы буенча Россиянең 10 шәһәре исемлегенә керүе.

Әлмәт муниципаль район Советы, район Башлыгының икътисади үсеш, социаль инфраструктура үсеше, инвестицион проектлар, муниципальара хезмәттәшлек булдыруда зур өлеш кертүен билгели.

Югарыда бәян ителгәннәрдән һәм Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезләмәләреннән чыгып

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башлыгының 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында отчетын исәпкә алырга.

2. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына Әлмәт муниципаль районы Башлыгы отчеты турында фикер алышканда кергән тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләүне һәм раслауны йөкләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин